ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.02.2022 ел Баулы шәһәре №24

Баулы муниципаль районы бюджетыннан
автомобиль транспортында шәһәр һәм
шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар
буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне
һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик
затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның
пассажирларның яңа коронавирус инфекциясенә
каршы вакцинация узуын раслаучы яки күрсәтелгән
авыруны кичерүен раслаучы шәхси QR-кодларын,
яңа коронавирус инфекциясенә каршы
вакциналаштыруга медицина каршылыгы булуны
раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодларын
тикшергән хезмәткәрләренең хезмәтенә түләве
чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү
тәртибен, нигезләмәсен һәм комиссия составын
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 нче маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне, шул исәптән юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча, метрополитенда даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның пассажирларның яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуын раслаучы яки күрсәтелгән авыруны кичерүен раслаучы шәхси QR-кодларын, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакциналаштыруга медицина

каршылыгы булуны раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодларын тикшергән хезмәткәрләренең хезмәтенә түләве чыгымнарын каплауга субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бүлүне раслау турында” 2022 елның 7 февралендәге 172-р номерлы күрсәтмәсе Нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Баулы муниципаль районы бюджетыннан автомобиль транспортында шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның пассажирларның яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуын раслаучы яки күрсәтелгән авыруны кичерүен раслаучы шәхси QR-кодларын, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакциналаштыруга медицина каршылыгы булуны раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодларын тикшергән хезмәткәрләренең хезмәтенә түләве чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта);

- Баулы муниципаль районы бюджетыннан автомобиль транспортында шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның пассажирларның яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуын раслаучы яки күрсәтелгән авыруны кичерүен раслаучы шәхси QR-кодларын, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакциналаштыруга медицина каршылыгы булуны раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодларын тикшергән хезмәткәрләренең хезмәтенә түләве чыгымнарын каплауга хокуклыларны сайлап алу комиссиясе турында нигезләмә (2 нче кушымта);

- Баулы муниципаль районы бюджетыннан автомобиль транспортында шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның пассажирларның яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакцинация узуын раслаучы яки күрсәтелгән авыруны кичерүен раслаучы шәхси QR-кодларын, яңа коронавирус инфекциясенә каршы вакциналаштыруга медицина каршылыгы булуны раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодларын тикшергән хезмәткәрләренең хезмәтенә түләве чыгымнарын каплауга хокуклыларны сайлап алу комиссиясе составы (3 нче кушымта);

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында

(http://www.bavly.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров